КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 март г.Казань № 231

Йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү турында

Йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алу чыгымнарына түләү өчен гражданнарга адреслы ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче түбәндәге затларга бер йорт биләмәсе өчен башкарылган чыгымнар, әмма иң күбе 100 мең сум күләмендә субсидия (алга таба – субсидия) билгеләргә:

Бөек Ватан сугышы ветераннарына;

хәрби хәрәкәтләр ветераннарына;

һәлак (вафат) булган сугыш инвалидларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, хәрби хәрәкәтләр ветераннарының гаилә әгъзаларына;

I һәм II төркем инвалидларына;

инвалид балалары булган гаиләләргә;

18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләргә;

җан башына уртача кереме 19 мең сумнан артмаган гаиләләргә;

Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә түбәндәге катнашучылар гаиләләренә:

хәрби хезмәткәрләр (шул исәптән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган хәрби хезмәткәрләр, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар);

Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче затлар;

махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнары;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының (Татарстан Республикасындагы эчке эшләр органнарының), Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре.

2. Бу карарга теркәлгән Йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

3. Субсидия бирү турында мәгълүмат Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла дип билгеләргә. Әлеге мәгълүматны Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру (аннан алу) «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 11 март, 231 нче
карары белән расланды

# Йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү тәртибе турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплау өчен түбәндәге гражданнарга (алга таба – гариза бирүче) субсидия (алга таба – субсидия) бирү тәртибен һәм шартларын билгели:

даими яшәү урыны буенча яшәгән, Бөек Ватан сугышы ветераннары, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашучылар, һәлак (вафат) булган сугыш инвалидларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, хәрби хәрәкәтләр ветераннарының гаиләләре әгъзалары, I һәм II төркем инвалидлар, инвалид балалар булган йорт биләмәләре милекчеләренә;

даими яшәү урыны буенча яшәгән, гаилә составында Бөек Ватан сугышы ветераннары, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашучылар, I һәм II төркем инвалидлар, инвалид балалар, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк балалар, һәлак (вафат) булган сугыш инвалидларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, хәрби хәрәкәтләр ветераннарының гаилә әгъзалары булган йорт биләмәләре милекчеләренә;

даими яшәү урыны буенча яшәгән, гаиләнең җан башына уртача кереме 19 мең сумнан артмаган йорт биләмәләре милекчеләренә.

Гариза бирүченең гаилә составы Россия Федерациясе Торак кодексының 31 статьясы нигезендә билгеләнә.

Йорт биләмәсе дигәндә җир кишәрлегендәге индивидуаль торак төзелеше объекты яки блоклап салынган төзелешнең торак йорты һәм аларга тоташа торган һәм (яки) индивидуаль торак төзелеше объекты яки блоклап салынган төзелешнең торак йорты белән уртак аерым торган ишегалды корылмалары (гараж, мунча (сауна, бассейн), теплица (кышкы бакча), йорт терлеген һәм кош-кортлар асрау урыннары, башка объектлар) аңлашыла.

1.2. Субсидия 2021 елның 21 апреленнән соң йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән шартнамә булу шарты белән бирелә.

1.3. Субсидия бер йорт биләмәсенә бер тапкыр бирелә.

Субсидия Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бер тапкыр түләнә торган субсидия бирү турында» 2022 ел, 18 февраль, 137 нче карары нигезендә йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бер тапкыр түләнә торган субсидия алган гражданнарга әлеге Нигезләмә нигезендә бирелми.

1.4. Субсидия бер йорт биләмәсе өчен башкарылган чыгымнар, әмма иң күбе 100 мең сум күләмендә бирелә.

Субсидияләнергә тиешле чыгымнар кыйммәтенең исәп-хисабында җир кишәрлеге чикләре эчендә газлаштыру (газ кертү урыннарын һәм йорт эчендәге газ челтәрләрен булдыру) буенча проект һәм төзелеш-монтаж эшләре кыйммәте, йорт эчендәге газ җиһазын (һәр төрнең иң күбе бер төрен) һәм газны исәпкә алу приборларын сатып алу исәпкә алына.

Субсидияләнергә тиешле йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ уздыру буенча проект һәм төзелеш-монтаж эшләре исемлегенә (алга таба – йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ уздыру эшләре) түбәндәгеләр керә:

газлаштыру проектын эшләү;

җир кишәрлеге буйлап газүткәргеч (җир өсте яисә җир асты ысулы белән) сузу;

эчке газүткәргечләрне сузу;

кухняны төзекләндерү һәм котельня урнаштыру (газ куллану җиһазын урнаштыру, газүткәргеч кертү урыннарын әзерләү, төтен чыгару юлларын һәм вентиляция каналларын төзекләндерү);

кайнар су белән тәэмин итү контурын су белән тәэмин итү өчен суүткәргеч сузу һәм җылылык системасы контурына су тутыру һәм кирәк вакытта аңа өстәп тору җайланмасын кую.

Сатып алган өчен субсидия бирелергә тиешле йорт эчендәге газ җиһазы исемлегенә (алга таба – йорт эчендәге газ җиһазы) түбәндәгеләр керә:

газ счетчигы;

газ плитәсе;

җылылык генераторы;

газлану сигнализаторы.

1.5. Гариза бирүче гаиләсенең уртача җан башына керемен исәпләгәндә даими яшәү урыны буенча аның белән бергә яшәүче гражданнар исәпкә алына. Аерым яки бергә яшәүгә карамастан ир белән хатынның һәм аларның балигъ булмаган балаларының керемнәре исәпкә алына.

Гаиләнең уртача җан башына керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган гаилә составына түбәндәгеләр керми:

тулысынча дәүләт тәэминатында булган затлар (опекадагы балалардан тыш);

хәрби хезмәткә чакыру буенча хәрби хезмәт узучы затлар, шулай ук хәрби һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирелә торган хәрби белем бирү оешмаларында белем алучы һәм хәрби хезмәт узу турында контракт төземәгән хәрби хезмәткәрләр;

иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәгән затлар;

суд карары буенча мәҗбүри дәвалануда булган затлар;

сак астына алу рәвешендә чикләү чарасы кулланылган затлар.

1.6. Субсидия бирү максатларында гаиләнең уртача җан башына кереме, Россия

Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен гаиләнең җан башына уртача керемен һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге турында» 2003 ел, 20 август, 512 нче карары белән расланган дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен гаиләнең җан башына уртача керемен һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлегендә күрсәтелгән керемнәр төрләрен исәпкә алып, «Аз керемле дип тану һәм дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен гаиләнең җан башына уртача керемен һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләү һәм аларның керемен исәпкә алу тәртибе турында» 2003 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 5 – 12 статьяларында билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләп чыгарыла.

Субсидия биргәндә гаиләнең җан башына уртача кереме субсидия бирү турында гариза биргән ай алдындагы айга кадәрге соңгы 12 календарь ай (алга таба – керемнәр исәпкә алына торган исәп-хисап чоры) өчен гаилә әгъзаларының керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.

Керемнәр исәпкә алына торган исәп-хисап чорында гаиләнең җан башына уртача кереме гаиләнең уртача айлык җыелма керемен гаилә әгъзалары санына бүлү юлы белән исәпләп чыгарыла.

Керемнәр исәпкә алына торган исәп-хисап чорында гаиләнең уртача айлык җыелма кереме гаиләнең барлык әгъзаларының уртача айлык керемнәре суммасына тигез була.

Гаиләнең һәр әгъзасының уртача кереме керемнәр исәпкә алына торган исәп-хисап чоры дәвамында аның алынган керемнәре суммасын әлеге керемнәр алынган исәп-хисап чоры айларына бүлү юлы белән билгеләнә.

1.7. Субсидия бирү турында карар гариза бирүченең яшәү урыны буенча «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлегендә (алга таба – Үзәк бүлеге) кабул ителә.

## II. Субсидия бирү тәртибе

2.1. Субсидия бирү өчен гариза бирүче, гариза бирүченең законлы вәкиле яки Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

гариза бирүче белән даими яшәү урыны буенча бергә яшәүче гражданнарны һәм банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча субсидия бирү турында гариза;

2021 елның 21 апреленнән соң подряд оешмасы белән йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрү эшләрен башкару турында төзелгән подряд шартнамәсенең күчермәсен;

йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрү буенча башкарылган эшләр актының күчермәсен;

йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрү буенча башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган документларны;

паспортларның күчермәләрен теркәп, сатып алынган йорт эчендәге газ җиһазы өчен түләүне раслый торган документларны;

төзелеп беткән газ бүлү системасы объектын кабул итү актының яки якларның мөлкәт кемгә каравын һәм эксплуатация җаваплылыгын чикләү турында мәгълүмат бирелгән тоташтыру (технологик тоташтыру) турында актның күчермәсен;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокукы теркәлмәгән торак урынга хокукны билгели торган документның күчермәсен;

Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украина территорияләрендә үткәрелә торган махсус хәрби операциядә катнашучылар гаиләләренә субсидия билгеләү өчен гариза бирүченең яки аның гаилә әгъзаларының Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украина территорияләрендә үткәрелә торган махсус хәрби операциядә катнашуын раслый торган документның күчермәсен;

Бөек Ватан сугышы ветераннарына, хәрби хәрәкәтләр ветераннарына, һәлак (вафат) булган Бөек Ватан сугышы инвалидларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, хәрби хәрәкәтләр ветераннарының гаилә әгъзаларына субсидия билгеләү өчен гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының Бөек Ватан сугышы ветераннары, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, һәлак (вафат) булган Бөек Ватан сугышы инвалидларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, хәрби хәрәкәтләр ветераннарының гаилә әгъзалары категориясенә каравын раслый торган документның күчермәсен;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында документның һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсенең (булганда) күчермәсен;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән никахлашуны (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында документның һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсенең (булганда) күчермәсен;

гариза бирүченең гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән (ялгыз яшәүче гражданнардан тыш) түбәндәгеләрне раслый торган документ (документлар) (ирекле рәвештә):

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы булуын;

шәхси мәгълүматны органга яки оешмага тапшырганда гариза бирүченең алар исеменнән эш итүгә вәкаләтен;

Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычлы затлар өчен ышанычнамәнең күчермәсен;

Әлеге Нигезләмәнең 1.1 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән гариза бирүчеләр, барлыкка килгән тормыш хәлләренә карап, өстәмә рәвештә түбәндәге документларны тапшыра:

гариза бирүченең һәм (яки) аның гаилә әгъзаларының тулысынча дәүләт тәэминатында булуы турында (опекадагы балалардан тыш);

гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яки көндезге уку формасында югары белем бирү мәгариф оешмасында гариза бирүченең һәм (яки) аның 23 яшьтән кечерәк гаилә әгъзаларының белем алу факты турында;

гариза бирүче һәм (яки) аның 23 яшьтән кечерәк гаилә әгъзалары һөнәри белем бирү оешмасында яки көндезге уку формасында югары белем бирү мәгариф оешмасында укыган очракта стипендия алмау факты турында;

гариза бирүченең һәм (яки) аның гаилә әгъзаларының хәрби хезмәткә чакыру буенча хәрби хезмәт узу турында;

гариза бирүченең һәм (яки) аның гаилә әгъзаларының суд карары буенча мәҗбүри дәвалануда булуы турында;

гариза бирүчегә һәм (яки) аның гаилә әгъзаларына карата сак астына алу рәвешендә чикләү чараларын куллану турында;

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучыларга, фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге формада белем алучы аспирантларга, дини мәгариф оешмаларында белем алучыларга түләнә торган стипендияләр, шулай ук гражданнарның әлеге категорияләре медицина күрсәткечләре буенча академик ялда булган чорда аларга компенсация түләүләре күләме турында;

отставкага чыккан судьяларның ай саен бирелә торган гомерлек акча күләме;

хәрби хезмәттән, Россия Федерациясенең җинаять-үтәтү системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Федераль куркынычсызлык хезмәте органнарында, дәүләт саклау органнарында, Россия Федерациясенең эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясенең таможня органнарында, Россия Федерациясенең милли гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясенең мәҗбүри башкару органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар буенча баш идарәсендә, шулай ук Россия Федерациясе законнарында хокук саклау эшчәнлегенә бәйле дәүләт хезмәте узу каралган башка органнарда хезмәт итүдән азат ителгәндә бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында;

хәрби хезмәт, Россия Федерациясенең җинаять-үтәтү системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Федераль куркынычсызлык хезмәте органнарында, дәүләт саклау органнарында, Россия Федерациясенең эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясенең таможня органнарында, Россия Федерациясенең милли гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар буенча баш идарәсендә, шулай ук Россия Федерациясе законнарында хокук саклау эшчәнлегенә бәйле дәүләт хезмәте узу каралган башка органнарда хезмәт итүче (хезмәт иткән) затлар тарафыннан пенсия күләме турында;

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясенең эчке эшләр органнары, Россия Федерациясенең җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясенең таможня органнары һәм Россия Федерациясе законнарында хокук саклау эшчәнлегенә бәйле дәүләт хезмәте узу каралган башка органнар хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты (гомуми хезмәт хакы) булып торган керемнәре, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән даими характердагы өстәмә түләүләр һәм азык-төлек тәэминаты (азык-төлек паегына алмашка акчалата субсидия) күләме турында;

Россия Федерациясенең җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, федераль куркынычсызлык хезмәте органнары, дәүләт саклау органнары, Россия Федерациясенең эчке эшләр органнары һәм Россия Федерациясе законнарында хокук саклау эшчәнлегенә бәйле федераль дәүләт хезмәте узу каралган башка органнар хезмәткәрләренең (хәрби хезмәткәрләрдән, Россия Федерациясенең милли гвардия гаскәрләре, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнары, Россия

Федерациясенең таможня органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар буенча баш идарәсе хезмәткәрләреннән башка) керемнәре турында;

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясенең милли гвардия гаскәрләре, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясенең таможня органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар буенча баш идарәсе хезмәткәрләренең керемнәре турында;

дәүләт бурычларын яки иҗтимагый бурычларны үтәгән вакытта дәүләт органы яки иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган һәм алынган субсидия күләме турында;

гариза бирүче яки аның гаилә әгъзалары тарафыннан Россия Федерациясеннән читтә алынган керемнәр күләме турында;

«Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган хосусый практиканы һәм керемнәрне гамәлгә ашырудан керемнәр күләме турында;

эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашырудан керемнәр (крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат булып оешмыйча төзелгән крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлегенә бәйле алынган керемнәрне кертеп) һәм хосусый практиканы гамәлгә ашырудан керемнәр турында;

гариза бирүче яки аның гаилә әгъзалары тарафыннан алына торган алиментлар күләме турында;

акцияләр буенча керемнәр һәм оешма милке белән идарә итүдә катнашудан башка керемнәр турында;

кредит оешмаларына акча салудан алынган процентлар турында;

авторлык заказы, акыл эшчәнлеге нәтиҗәләренә махсус хокук бирү турындагы шартнамәләр буенча керемнәр турында;

мирас итеп алына торган һәм бүләк ителгән акча турында;

милектә Россия Федерациясе Салым кодексының $217^1$ статьясында күрсәтелгән ия булу срогыннан кимрәк булган күчемсез мөлкәтне реализацияләүдән, шулай ук мөлкәтне арендага (наемга, өстәмә наемга) бирүдән алынган керемнәр турында.

Субсидия бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүчеләр паспортын яки шәхесне таныклый торган башка документын күрсәтә.

Гариза почта аша җибәрелгәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.

2.2. Үзәк бүлеге ведомствоара рәсми сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә субсидия бирү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматны ала:

яшәү урыны буенча теркәлү турында;

инвалидлык һәм аның төркеме булу турында (булганда);

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

никахлашуны (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында;

үлемне дәүләт теркәвенә алу турында;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокукы теркәлгән торак урынга милек хокукы турында;

балага опека билгеләү турында;

ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында; ата-ана

хокукларын чикләүне гамәлдән чыгару турында белешмә, баланың гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда аны тартып алу турында белешмә;

хезмәт бурычларын яки башка бурычларны үтәгән өчен акчалата бүләкләү (стимул бирү характерындагы түләүләрне кертеп), башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт, гражданлык-хокукый шартнамә кысаларында гамәлләр кылу өчен акчалата бүләкләү турында;

Россия Федерациясе законнары һәм (яки) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган пенсия, пособиеләр һәм башка шундый түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминият түләүләре һәм компенсация характерындагы түләүләр суммалары турында;

керемнәр исәпкә алына торган исәп-хисап чорында эшкә сәләтсез затларны карауны гамәлгә ашыру турында.

Гариза бирүчеләр яки алар ышанычнамә нигезендә вәкаләт биргән затлар әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәгә ия документларны үз инициативасы белән Үзәк бүлегенә тапшырырга хокуклы.

2.3. Әлеге Нигезләмәнең 2.1 һәм 2.2 пунктларында күрсәтелгән һәм тапшырылган документлар һәм белешмәләр нигезендә Үзәк бүлеге субсидия бирү турында гариза теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидия бирү турында яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Гариза бирүчегә субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында хәбәр итү аны бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көнне гариза бирүче тарафыннан субсидия бирү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы белән язма рәвештә, электрон почта адресы белән электрон документ рәвешендә) гамәлгә ашырыла.

2.4. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;

әлеге Нигезләмәнең 1.1 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән гариза бирүчеләр өчен гаиләнең җан башына исәпләнгән уртача кереме күләме 19 мең сумнан арту;

гаризада дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмә булу;

әлеге Нигезләмәнең 1.1 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән гариза бирүчеләрнең һәм (яки) аларның эшкә сәләтле гаилә әгъзаларының түбәндәге очраклардан тыш керемнәре булмау:

гариза бирүче яки аның эшкә сәләтле гаилә әгъзасы өч яшькә кадәрге бала карауны гамәлгә ашыра;

гариза бирүче яки аның эшкә сәләтле гаилә әгъзасы 1 төркем инвалидны, 18 яшькә кадәрге инвалид баланы, шулай ук дәвалау учреждениесенең бәяләмәсе буенча даими чит кеше каравына мохтаҗ йә 80 яшькә җиткән картларны карауны гамәлгә ашыра;

гариза бирүче яки аның эшкә сәләтле гаилә әгъзасы гомуми белем бирү оешмасында, яисә һөнәри белем бирү оешмасында, яисә югары белем бирү мәгариф оешмасының көндезге бүлегендә укый һәм стипендия алмый.

## III. Йомгаклау нигезләмәләре

3.1. Гариза бирүче тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук алар күрсәтелгән документларның төп нөсхә булуы өчен җавап бирә.

3.2. Гариза һәм субсидия алу өчен кирәкле документлар (белешмә) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Электрон документлар рәвешендә бирелә торган гаризалар һәм документлар (белешмәләр) Россия Федерациясе законнары нигезендә гади электрон имза белән имзалана һәм электрон мәгълүмат саклагычлардан һәм гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән («Интернет» челтәрен кертеп) файдаланып тапшырыла.

3.3. Гариза һәм субсидия алу өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) бирү гариза бирүченең субсидия алу максаты белән үз шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгын раслау булып тора.

3.4. Дөрес булмаган белешмәләр бирү, субсидия алу хокукына йогынты ясый торган мәгълүматларны яшерү аркасында субсидиянең нигезсез түләнгән суммасы гариза бирүче тарафыннан Үзәк бүлегенең тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең казначылык счетына акча күчерү юлы белән ирекле рәвештә кире кайтарыла.

Гариза бирүче тарафыннан әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогы бозылганда Үзәк бүлеге субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.